**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 июнь № 388

г. Казань

Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 294 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү тәртибен расларга (карарга теркәлә).

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\388.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 14 июнь, 388 нче
карары белән расланды

Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен 2017 елда авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

Авиация хезмәте буларак ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү максатларында 2014 елның 1 гыйнварыннан башлап Россия Федерациясе территориясендә башкарылган, медицина модуле белән җиһазландырылган гражданнар һава судносының (вертолет) очуын гамәлгә ашыру аңлашыла.

2. Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелгән субсидия (алга таба – субсидия) һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – Фонд, бюджетара трансфертлар) рәвешендә бирелә.

4. Бюджетара трансфертларны тоту Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итүгә Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре күләме 2017 елга авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәте күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативларыннан һәм очулар саныннан чыгып билгеләнә.

Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәте күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә төзелә торган 2017 елга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша Татарстан Республикасы медицина оешмаларын нигездә бер каналлы финанслауны тормышка ашыруга Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме

өчен түләү тәртибен һәм тарифларын билгеләү турында тариф килешүе белән раслана.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы агымдагы айның 20сенә кадәр бюджетара трансфертларны Фондның бюджет заявкалары нигезендә 2017 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы җиткергән финанслауның иң чик күләмнәре чикләрендә Фонд бюджетына бирә.

7. Фонд:

законнар нигезендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – медицина оешмасы) белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бертип форма буенча авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү турында шартнамә төзи;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ай саен, агымдагы айның 15еннән дә соңга калмыйча, бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет заявкасын кертә;

медицина оешмасы түбәндәге шартларны үтәгәндә аңа акча күчерә:

Фонд күчергән акчаны Авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуга тоту;

авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алу буенча аерым исәп-хисап алып бару;

Фондка хисап аеннан соң килә торган айның биш эш көненнән дә соңга калмыйча авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтүгә авиация хезмәте өчен түләүгә счетлар реестрын һәм счетларны тапшыра.

8. Медицина оешмасына аванс бирү Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар күчерелгән көннән соң биш көн эчендә Фонд тарафыннан авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтүгә билгеләнгән планлаштырылган йөкләмәнең (алга таба – планлаштырылган йөкләмә) уртача айлык күләменнән 50 процент күләмендә гамәлгә ашырыла.

Фонд медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган счетлар реестрына билгеләнгән тәртиптә медицина-икътисадый экспертиза үткәрә һәм, түләнгән авансны исәпкә алып, ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20 сеннән дә соңга калмыйча аларга түли. 2017 елның декабрендә авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итү өчен Фонд 2017 елның 26 декабреннән дә соңга калмыйча, алдан түләнгән авансны исәпкә алып, медицина учреждениесе тапшырган заявка нигезендә билгеләнгән планлаштырылган йөкләмәнең уртача айлык күләмендә медицина оешмасына акча күчерә.

9. Медицина оешмасы алган акчаны авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алу чыгымнарына түләү өчен юнәлдерелә.

10. Медицина оешмасы квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның бишесеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән формалар буенча хисаплар тапшыра:

авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчадан файдалану турында;

субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында.

11. Фонд ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның бишесеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны финанслар белән тәэмин итүгә Фонд җибәргән бюджетара трансфертларны тоту турында хисап тапшыра.

12. Бюджетара трансфертлардан максатка ярашсыз файдалану бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

13. Фонд тарафыннан 2018 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар 2018 елның беренче 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Әлеге Тәртип нигезендә алынган һәм файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кайтарылырга тиеш.

15. Фонд түбәндәге очракларда медицина оешмасының бирелгән акчаны өлешчә яки тулысынча кире кайтаруын тәэмин итә:

әлеге акчага ихтыяҗ булмавы (кимүе);

медицина оешмасының дөреслеккә туры килмәгән хисаплылык тапшыруы;

медицина оешмасының акчадан максатка ярашсыз файдалануы.

16. Медицина оешмасына бирелгән акча әлеге Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән очракларда Фондның тиешле таләбен алган көннән соң 15 көн эчендә Фонд бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмасы акчаны кайтару вакытларын бозганда Фонд әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң 30 көн эчендә акчаны Фонд бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

17. Фонд әлеге Тәртипнең 15 нче пунктында каралган нигезләр буенча медицина оешмасыннан килгән акчаны әлеге акча Фондның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерелгән көннән

соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтаруны гамәлгә ашыра.

18. Фонд, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы авиациядән файдаланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация хезмәтен сатып алуны оештыру өчен медицина оешмасына килгән акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

19. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган тәртиптә һәм формаларда хисаплар тапшыра:

субсидия аларны финанслашу максатларында бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында;

субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында.

20. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына хисап финанс елыннан соң килә торган финанс елының 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча субсидия бирү шартларын үтәү турында хисап тапшыра.

21. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, медицина оешмасына һәм Фондка йөкләнә.

---

F:\KARAR\2017\388.doc